**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Школьная, дом 8, село Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 8 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс 8439642223 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

**№33** **17.06.2021ел**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 45 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында» 778 номерлы указын, «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» һәм коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 45 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертергә, 3 бүлекнең «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә әлеге алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен гомуми керемennән артып китсә һәм алыш-биреш ясалган чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.И.Фәтхетдинов